СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а,д.Нижние Аты
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35. E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

## Урта Аты авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**22.09.2017** **№44**

### Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдумны түбәндәге сорау буенча уздыруны инициацияләргә: «2018 елда Урта Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме ?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - урам яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру; Тубән Аты авылы Урта Аты авылы<br>- каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча туплау урыннарын тоту, трактор белән чүп-чарны тыгызлау: Тубән Аты ,Урта Сәрдә авыллары<br>-Кылачы авылы купере очен материаллар сатып алу һәм ремонлау. |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Вак таш сатып алу, юл-урам челтәренә вак таш салу: Тубән Аты ,Урта Сәрдә ,Клачы авыллары |
| | | |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “ЮК”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Тубән Аты авылы, Үзәк ур., 37 йорт; ТР, Арча районы, Урта Сәрдә ав., Үзәк ур., 70 А йорт.,РТ,Арча районы ,Кылачы авылы ,Аяк киеме урамы ,16 йорт .

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы: Батталова Р.Х